# КӘЛӘПҮШЧЕ КЫЗ

*Хөрмәтле укучым!*

*Үземнең күңелемнең йемешен сезгә тәкъдим итәм. Бу хикәядә язылган сүзләр, тасвир кылынган хәлләр димагымның тәфкираты улдыгы өчен кыямәтә кадәр калдырачак ядкәрләремнән бередер. Бәлки сез мине юк нәрсәләр язып вакытын әрәм иткән, гомерен заигъ кылган дип кызганырсыз да; ләкин ул вакытта айаначак кеше мин улмаенча сез улырсыз, әфәндем. Чөнки сезнең ул халәтеңез әдәбият нәдән гыйбарәт идекене белмәдекеңезне белдерәдер. Бәлки укыдыгыңыз илә: «Бу хәлләрне кайдан белгән, бу хәлләрне ничек аңлаган? Әлбәттә, үзе дә хикәянең икенче дәрәҗә каһарманы Вафа мәсләкендә булырга кирәк» — дип бер хөкем чыгарырмысыз? Ләкин, борадәрем, хата итәсез, зира бер нәрсәне белү өчен мотлак үзең кылу лязем түгелдер. Сезнең бу сүи заныңызда үзеңезнең әдиплек, мөхәррирлек нәдән гыйбарәт вә әдипләр нә тарызда яздыкларыны белмәдекеңез өчен улдыгындин тагы бер мәртәбә кызганамын. Һәр язылган сүз үз вакыйгаларын тасвир, үз хәлләрен бәян улмаз! Хосусән, мөхәррирләр, шагыйрьләр ни язсалар, кемне тасвир кылмакчы булсалар, шул кеше булып күп сүзләр сөйләрләр һәм сөйләтерләр. Бу сүзләрнең бәгъзеләре әшәке улсалар да, мөхәррирнең үзенең фикеренең шулай булуын белгертмәйдер. Хәтта бәгъзе мөхәррирләр үзләре дә кылган итеп тә язалар. Мәсәлән, мин:*

*«Сөйдем сине, шуныңлә әүвәрә булдым.*
*Аерылдым синдин, дәрдеңлә дивана булдым»*

*дисәм, бер вакытны гыйшыкның әсире улмыш икән дә, никадәр җәфалар чикеп аерылган икән дип хөкемме идәрсең? Гаҗәба, шуның артыннан ук шигыремне әйтсәм, ни диерсез:*

*«Егет улдым, гомеремдә берсене сөймәдем,*
*Гыйшык, дәрд дип, Мәҗнүн кеби дивана улмадым».*

*Бусына карап гомеремдә бер кәррә улса да гыйшык ләззәтен татымадыгым илә хөкем идәрмесез? Шул бәянларымнан мәгълүмдер ки, һәр язылганны үз хәле тасвир димәк бөек хатадыр.*

*Укучым! Минем бу хикәяне язудан мәкъсудым — Камәр кеби булуның ахыры ни булачагын күрсәтеп, милләтемнең туташларын шул кара бәхетләрдән коткарыр өчен, аларга Камәр булуда нинди авырлыклар барлыгын белдереп, үзләрен саклар өчен бер тәнбиһдер.*

Мөхәммәдгаяз.

*«Кәләпүшче кыз» минем элеккеге әсәрләремдин булдыгындин, әлбәттә, бик күп йерләрендә кимчелекләре бардыр. Кимчелекләренә карамаенча, маэленә карап укыган кариэләремә бик мөтәшәккирмен. Мондый кешеләр күплегендин әүвәлге басылуында китабым бик тизлек илән таралып бетте. Бу көннәрдә сораучылар күптин күп арттыгындин икенче мәртәбә бастырмакчы булдым.*

*«Кәләпүшче кыз» тугрысында шифаһи һәм тәхрирән бик күп тәкьризатлар алсам да, берсен дә китабыма дәрҗ кылмадым. Фәкать шул арада гына алдыгым бер хат дикъкатемне җәлеп итдегендин, укучыларыма күрсәтер өчен, бергә бастырачак улдым һәм китабымның ахырына гыйлавә кылдым.*

Мөхәммәд Гаяз ибн мелла Гыйлаҗетдин әл-Исхакый

1902. 21 нче февраль.

## I

Камәр һаман унбиш яшенә йетәр-йетмәс һәр кешегә бик кадерле, бәһасез яшьлек заманнары йеткән вакытта атасыз калып ятимә исемен алган иде. Атасыннан калган бераз акча, йорт җиһазлары Камәр, анасы Кәримә өчен

гомер үткәрерлек, дөнья уздырырлык булмавы тормышларын бөтенләй бозган, Камәрнең дә сәгадәтен, рәхәтен җуйган иде. Кәримә бала җанлылыгы, йомшак күңеллелеге илә, ире мәрхүм Габдерәшиткә дөрест мәхәббәте өчен, һәрникадәр иргә китмәенчә, ике бөртек газиз балаларын тәрбиягә гомерен сарыф кылмакчы булса да, бердән, дәүләт юклыгы, икенчедән, 32-33 тән үтмәгән яшьлеге, гүзәллеге бу уена юл бирмәүдә иде. Кәримә балаларын бик якын күргән шикелле, балалары да ата урынында тәрбия кылучылары да шул булганга, ата мәхәббәтен дә аналарына биреп сөюдә иделәр. Ашау-эчүләрендә һәрвакыт ят кеше булмаганга рәхәтләнешеп торып, аталары искә төшкәндә берсенең татлы яше башкаларына рәхәт биргәнгә, кай вакытларда Габдерәшит абзый өендә гөнаһсыз балалар берлә бер тол хатыннан аккан күз яшьләре бик куркынычлы күренешләр, кызганыч манзаралар күрсәтүдә иде. Кәримә үзенең уңганлыгыннан файдаланмакчы булып, дөнья уздырырга бер эш булсын, тамак туйдырырга бер кәсеп булсын дип, кәләпүш эшләргә тотынган иде. Һәм Камәрне дә үзе берлә бергә эшкә өйрәтә иде. Угылы Габделахәт кибеткә чыгарып эшләрен акчага, товарга алмаштырып гомер үткәрә башлаганнар иде. Шуның өчен Кәримә кәләпүшче хатын, Камәр дә кәләпүшче кыз булган иде. Кәримә бу көенчә балаларын тәрбия кылырлык акча ясый алса да, иренең вафатына вакытлар үткәнгә, гомер үткән саен бер яктан мәхәббәт суынып, бер яктан ирнең кирәклеген сизә башлаганга, Кәримәнең күңелендә аналык шәфкате берлә иргә бару дәрте бер-берсе берлә сугышуда иделәр. Камәр берлә Габделәхәтнең хәлләрен уйлаганда Кәримәнең күңелендә аналык шәфкате урнашып, иргә бармаска кистерсә дә, киләчәктәге егерме-утыз ел гомерен ирсез уздыруны исенә төшерсә, чыдый алмавын белеп, кайвакыт булса да бер иргә барырга тиеш буласын төшенеп, яшьрәк вакытта баруын артык күргәнгә, шул арада кияүгә китү уе да бар иде. Һәм Кәримәнең уңганлык, матурлык берлә исеме китүе, иргә бару хәбәре чыкса, чибәррәк йерләрдән җаучылар килүенә дә ышандырган иде. Алай булса да Камәрнең һаман бирерлек булмавы, Габделәхәтнең дә бер эш булдырырлык булып мәктәптән чыкмавы, ничек булса да аларга бер асраучы кирәк булуы Кәримәнең күңелендә бер

хәсрәт, эчендә бер төен иде. Бара-тора Кәримә китү уен корды. Камәр берлә Габделәхәт хакында ни эшлисен кистермәсә дә, Камәрне үзе берлә бергә алмакчы, Габделәхәтне дә, мәктәптән алып, асраугa бирмәкче иде. Габдерәшитнең: «Ничек булса да угылымны укыт!» васияте исенә төшеп, Габделәхәтнең дә тырышлыгы, япьтәшлеге берлә, укыта алса, зур кеше булачагын исәпләп, укытмый надан калдырып әллә нинди зур дәрәҗәләрдән буш калдырасын уйлап, укытырга теләсә дә, үзенең байлыгы юкка, барасы кешесе кем булса да дошманының ике баласын тәрбия кыла алмаганга, Габделәхәтне асраулыкка бирүне кистереп куйган иде.

Кәримәнең күңелендә иргә бару урнашканга, Габделәхәткә урын эзләргә тотынган иде. Балалары моннан хәбәрсез булсалар да, карендәш-кабиләсе Кәримәнең иргә китәргә теләвен аңлаганнар иде. Эзли торгач, Кәримә Габделәхәткә урын да тапты. Мәктәптән алып бирерлек үк булмаса да, Кәримәнең исәбе Габделәхәтне яхшы урынга кертү булмаенча, аннан аерылып бер генә балалы хатын исемен алып иргә китү эшен җиңеләйтү генә иде. Кәримә, эш җайлана торсын дип, Габделәхәтне бирмәкче булса да, мәктәптән сорамаенча чыгармаулары, Кәримәнең мәктәпкә барып яки мөгаллимне күреп соравын тиешләндергән иде. Габделәхәт бер мәктәптә укыган шикелле, Камәр дә, мөселман кызы булгач, билгеле бер остазбикә абыстайдан укый иде. Шәфкатьле ана бәгырь йемеше балаларының сабакларын тыңлатып, укырга мәхәббәт салуда иде.

Кәримә, күңелендәге серләрне сакларга кирәк икәнлеген белсә дә, Габделәхәтнең сабагын тыңлатканда: «Угылым, сабагыңны яхшы укыгансың! Рәхмәт, язуың да яхшырдымы?» — дип сүз башлады.

Габделәхәт: Хәлфә, яхшы, диде. Киләсе елга кибеттә тора алырсың, ди.

Кәримә: Быел ук тора алмасмыни? Хәлфә, Фәхри абзыйларга кибеттә торырлык булды инде, хисап та белә, счут та белә, язарга остарды, дигән. Шуның өчен Фәхри абзыйлар сине кибеткә сорыйлар, кибеттә тора алмаса, өй арасында гына йөреп торыр, диләр.

Габделәхәт: Мәктәптә укымаммыни? Аннан ары кем булырмын? Хәлфә,

безнең шикелле күп укысаңыз, сез дә шулай я мөдәррис, я мөгаллим булып рәхәтләнеп торырсыз, дия иде. Мин шулай булмаенча калырмынмыни?

Камәр эшнең төбен аңламаганга: Туган! Болай да бик уңайсыз шул! Әти булса укытыр да иде, кеше дә булыр идек, әнинең шул, күрәсең, алай ук озын укытырлык хәле юк. Укый алсаң да бер ел укырсың. Ахыры дөньяны әнигә генә ышанырга ярамый, дөнья уздырулар җиңел түгел, без шундый мәшәкатьләр күреп тә, авыш-тәүеш тора алсак, ярый инде.

Габделәхәт күзләрен яшәртеп: Әти бәгърем минем бә- хетсезлегемдин үлгән икән!

Камәр дә моңланып кына: Бәхетле булсак, үлмәс тә иде, үлсә дә бу кадәр тарлыкта, бу чикле фәкыйрьлектә калдырмас иде!

Кәримә: «Алла ни язган, шуны күрми хәл юк шул!» — дип еглый-еглый әйткәч, өчесе дә бердән акыртын гына татлы яшьләрен агызып киңәш итә башлаганнар иде. Кәримәнең күңелендә тулган, төенләнеп торган хиссиятләр чишелә башлады. Габдерәшитне искә төшереп: «Моннан бер ай элгәре әтиеңез сәламәт иде, кулымыз иркен иде. Чәй эчкәндә бер сезгә карап, бер мине карап рәхәтләнеп көлешеп утыра идек, гомеремезнең, дөньяга килүемезнең рәхәтен күрә идек, ярабби! Ярабби! Шул рәхәтле көннәрне дә син биргән идең, боларын да, Раббем, күрсәттең! Инде бердән бер угылымнан аерылам, белмим, киләчәктә ниләр күрермез? Уф, Раббем, үзеңә тапшырдым!» — дигәч, Габделәхәт әнисенең итәгенә ятып еглый башлагач, Камәр дә алсу йөзләреннән энҗе бөртеге төсле яшьләр агыза башлады, боларның бу хәсрәтле мәҗлесләре ахырыннан Габделәхәтнең күзләрен сөртеп: «Әни бәгърем! Еглама! Апакай, син дә тукта, керермен, Алла теләсә!» — сүзләре берлә тәмам булып, бер тол хатын берлә ятимә кызның, шәкерт баланың берсеннән-берсенең аерылулары кебек хәлләрне искә төшереп, өчесендә дә аерылышу кайгылары урнашуда иде. Габделәхәт күңеленнән һич разый булмаса да, анасы берлә тутасының гозерләрен тыңлап, аларның рәхәтләре өчен, үзенә никадәр авырлык килсә дә, «якыныңа җаныңны бир, ата-анаңа наныңны бир», — дип кермәкче булган иде. Габделәхәт кичтән бик соң йоклаганга, иртәгесен сабак вакытыннан бераз

кичегебрәк барган иде. Мәктәп гадәтенчә, мөгаллим кичегүенең сәбәбен сорагач, Габделәхәт кичәге вакыйганы баштан-аяк сөйләп биргән вә бу көннән башка сабакка да килә алмаячагын аңлаткан иде.

Мөгаллим: «Уку кирәк иде!» «Сабак укыган — сума җыйган, дөнья көткән — дин җуйган!» дигән сүзне ишеткәнең юкмыни? Укысаң менә зур кеше булыр идең», — дигәч, Габделәхәт, укыйсы бик килә дә, фәкыйрьлекләреннән укый алмый калуын күзләреннән яшьләр чыгарып белгерткән иде. Мөгаллим Габделәхәтне әрәм итәсе теләмәгәнгә: «Әниеңә әйт, без сине чыгармыйбыз, бер-ике ел укытабыз әле, аннан ары теләсә ни эшләр. Байлыгыңыз булмаса, аннан мәшәкать күтәртмәмез. Мин үзем аша- рыңа-эчәреңә табам. Менә бу көннән куна торган балалар янына килеп кун!» — дигәч, Габделәхәт шатланып: «Ярар!» — җавабын гына биргән иде. Һәм кайтып әнисенә,апасына сөйләгәч тә, Кәримә эшнең асылын белер өчен мөгаллимне барып күрсә дә, шул җавапны алгач, шатланып, иремнең дә васыятен тутырам, дип, әйберләрен хәзерләп мәктәпкә илткәннәр иде.

Кәримә, Габделәхәтне тапшыргач, эшенә каршы килүче булмаганга, шул арада ара-тирә хәбәр йөртә торганга, сораучыны да ошатканга, шул көннәрдүк китмәкче иде. Алай да, эшне бик ашыктырырга ярамый, дип, җаучыларга бераз көтәргә куша иде. Камәр атасыз калу кайгысын күргәнгә, туганыннан аерылганга, шул көннәрдүк анасы да иргә китсә, ярага тоз сипкән төсле булып, атасын сагынып, карендәшен айап, анасын көнләп сызып бетәчәк иде. Шуның өчен Кәримә бернәрсә дә белгертмәенчә, ис- кечә эшләрене караудa, һөнәрләр берлә тамак туйдыруда иделәр. Эшләгән кәләпүшләрне Сәлимовлар кибетенә биргәнгә, бу юлы Камәргә чыгарырга тиеш булган иде. Камәр, яшь булса да, кызлар исәбеннән санарлык булганга, кызлар аңлаганның һәркаюсын аңлый башлаганга: «Анда ир-ат янына ничек чыгыйм!» — дисә дә, анасы хәзер иргә китәргә хәзерләнә торган булганга, анда чыгып үзенең исемен югалтасы килми иде. Камәрнең исеме-чабы аннан да кадерлерәк икәнлеген белсә дә, яшьрәк әле дип, чыгар- макчы булган иде. Чыгармый хәле юк! Чыгармаса, акча юк, башка чыгарга кеше юк. Ай фәкыйрьлекниләр күрсәтә?! Шуның өчен шул:

«Ярлылык иман китерә, азгынлык иман бетерә!» — дигәннәр. Шулай итеп, Камәр Сәлимовлар кибетенә эш чыгарган иде.

## II

Сәлимовлар Казанның бик зур байларыннан булмасалар да, Печән базарында ике ишекле кибеттә читек-кәвеш, кәләпүш-калфак берлә сәүдә итәләр иде, кибетләрендә ике сатучы, өченчегә Сәлимовның угылы да бар иде, кибет счутлары барысы да баш сатучы Вафада иде. Вафа салада туган, салада үскән булса да, яшьтән Сәлимовларда хезмәт итә килгәнгә, зур приказчик булып дүрт йөз тәңкә еллык ала иде. Кечкенә вакытта салада чагында остазбикә абыстайдан гына укыган булса да, Казанга килгәч, язуга өйрәнер өчен бераз мәктәпкә дә йөргән иде. Агалары тәрбиясендә торганда русча укырлык вакыты булса да: «Урыс теле бернәрсә түгел ул, мин аны хәзер беләм!» — дип укымаенча, переводлардан гына хәреф өйрәнеп, бераз басма китаплар укый алырлык булган иде. Табигате бик гаҗәп, бик көлке кеше иде. Шулай бер-ике ел рәтсез-чиратсыз укуы берлән дә һәр эшкә катышырлык гыйлем бар дип белгәнгә, нинди мәсьәлә чыкса да, Вафа шул мәсьәлә тугрысында бер сүз сөйләми калмый иде. Һәм сөйләгән сүзләрен үзе дә дөрест дип белеп, һәр кешегә кабул иттерергә дә тели иде. Кыскасы гына, яңы чыккан мәсьәләләр хакында Вафаның бер уе, бер сүзе бар иде. Ысулы җәдид, ысулы кадим мәсьәләләрендер һәйәте җәдидә хакларында бер фикер сөйләүдә иде. «Ысулы җәдидтә уку-язу кирәк диләр, без кирәк түгел димез, һәйәте җәдидә хәрам ул, аңарга ияргә ярамый!» — сүзләре берлә бөтен базар халкын шаулата иде. Ишаннарга китсә, ул юлда аннан да белемле кеше юк — һәр ишан хакында бер төрле фикер асрый; бусы дөрест ишан, бусы түгел ди, бәгъзесен яманлап, бәгъзесен мактап йөри. Уйланмасын ки, барысының да мәҗлесендә булгандыр да бер төрле сынаган дип — хәтта төсләрен дә күргәне юк иде. Әмма политикага китсә, безнең Вафа бер дапломат киселә,

әнглиз политикасыннан көлә, Америка идарәсен сүгә, Австрияга килсә, аныңча, алардан зиһенсез, алардан тупой халык юк, имеш! Тарих-җәгъраФиядән һич курыкмый сөйли, аңар башка кеше сөйләсә, каршы төшә, кычкырып көлә, аныңча, йер такта төсле түшәлгән, уртасында кендеге бар, имеш! Йер түгәрәк, яссы түгел, безнең аста, түбән якта Америка дигән бер зур йер бар диелсә һәм исбат кылынса, Вафаны көлдерүдән башка эш булмаячак иде. Вафа динне ата-баба йоласыннан башка нәрсә түгел дип белгәнгә, яңырак мода киемнәр кигәнне фасикъ булган дип уйлаганга, һәрвакыт эше дә узган-барганны җентекләп, берсенә «киемең шәригатькә сыймый», икенчесенә «мыегың кырыкмаган», өченчесенә «бүркең очлы», дип бәйләнеп торудан бушанмый иде. Иске гадәтләргә аерым-аерым иманы булганга, дингә тияләр дип әллә ниләр чуалтып бетерә иде, бераз русча таныганга, белмәгән сүзләреннән әллә нинди мәгънәләр чыгарып халык арасында фетнә төшерергә теләсә дә, халык арасында күп сөйләве, сүзенең төпсезлеге берлә исеме китүе, шәригать эшләренең һәммәсенә катышуы, үзенә «абыз» Вафа исемен күтәртеп сөйләгән бер сүзе халык арасында «абыз» Вафа хәбәре!» дип һәркемне көлдерә генә иде. Хатын-кыз хакында бөтен дөньядагы матур хатын-кызны гүя Вафага гына рәхәт бирер өчен яратылган дип белеп, күргән бер чибәррәк хатын-кыз берлә аерым утырышлар ясарга тели һәм ясый иде. Ятимә Камәр дә туры ук эшләрен Вафага тапшырасы булганга, Вафа аңарга да, билгеле, башка хатыннарга кылган эшен эшләячәк иде. Камәрнең керүе берлә Вафаның җылтыраган күзләре Камәргә текәлгән, тәнендәге бөтен тамырлары селкенүгә килгән, күңелендә аз вакытта әллә никадәр уйлар йөргән иде. Камәрнең китергән кәләпүшләрен актара башлап: «Яхшы эшләмәгән икәнсез! Укалары эләгеп тә бетмәгән!» — дип, Камәргә карап сөйләшсә дә, кәләпүшне яратмаудан түгел, бәлки Камәрне сөйләтер өчен генә иде. Кәләпүш ни булса да булсын, Камәр сөйләсен дә, нинди кыз икәнлеген белсен!

Камәр: Үземезчә яхшы эшләдек иде.

Вафа: Үзеңезчә генә ярамый шул, бөтенләй яхшы булсын, кызлар төсле, шыгырдап торсын. Кызлар үзләре әйбер алганда егет сайлаган кебек бер йерен

яратмый, икенче йердән көлеп җөдәп чыгалар.

Камәр, егетләр берлә катыш юкка күрә, ул җайдан бер дә сүз сөйли белмәсә дә, табигатендә кызлык барга: «Шундый яхшы эшне кызлар түгел, егетләр дә яратыр инде».

Вафа: Алар ул чикле назлы булмыйлар, бер кызга күзләре төшсә, шуннан аерыла алмыйлар.

Камәр, кызарып, аңламаган булып: «Әни гел алганча әйберләр сорады, калганына акча сорады».

Вафа: Тукта әле, чибәр кыз, исемеңне дә белмим, сезнең элгәреге счутларыңыз да бетмәгән, зуррак эшеңез чыкса ярар иде, дип тора идем. Габделәхәткә ни булды, аны сөйләтеп булмый, менә синең берлә ни сөйләсәң дә ярый!

Камәр: Габделәхәт мәктәптә тора инде, өйгә бер дә кайтмый.

Вафа: Әйберләрне сез чыгарырсызмыни?

Камәр, кибеткә, әйберләргә күз төшереп: Әйе!

Вафа: Кибеттән бер-бер нәрсә аласыңыз бармы әллә? Кирәк булса, менә бик яхшы калфаклар! Сезнең төсле матур кызларга матурлык өстенә матурлык китерә!

Камәр, көлемсерәп: Бар да, хәзер алмыйм әле.

Вафа: Ник алмыйсыз?

Камәр: Шулай гына.

Вафа: Юк, алай булмый, акча юк, дисәңез, биреп торырга мөмкин.

Камәр: Акча, бирергә булгач, барыбер ул, булгач алырмын.

Вафа: Улсыннан курыкма, кирәк булса мин бирәм, акчасын бер вакытта бирерсез, ашыктырып сорамабыз.

Камәр: Әнигә әйтмәгән идем, калсын әле.

Вафа: Яшь вакытта барысын дә әниләргә киңәш итеп бетермиләр. «Кызлар күңеле кызган казан» дигән сүзне ишетмәдеңмени? Кызлар күнеленә барысы да сыя.

Камәр, сүзнең кая ауганын белеп: Була торгандыр, мин әни сүзеннән бер

дә чыкмыйм.

Вафа: Һәрвакыт әниең берлә тора алмассың ласак! Кияүгә китәргә вакытың җитәр, шул чакта да әниең сүзе берлә йөрерсеңмени?

Камәр: Әни сүзе берлә йөрсәм, харап булырмынмыни?

Вафа: Ата-ана сүзе берлә йөрсәң, алар сөйгәнеңнән аерып ятка да бирәләр!

Камәр: Минем сөйгәнем юк, тагы аналар ул тугрыда кызларына каршы килмиләр.

Вафа: Бигрәк үткен кыз икәнсез, бу тапкырлыгыңыз берлә дә сөйгәнеңез булмаса — гаҗәп!

Камәр: Минем эшемне бетерсәңез лә, китәр идем!

Вафа: Бигрәк ашыгасыз, әллә шул тозсызны күзем күрмәсен дисезме?

Камәр: Юк, алай әйтмим, эшем бар, кайтырга кирәк!

Вафа: Качанга чыгарырсыз?

Камәр: Эшләп бетергәч, — диде.

Вафа: «Алай да бик саргайтмаңыз!» Камәр әйберләрне алып китә башлагач, Вафа: «Исән булыңыз, чибәр кыз!» — дигәч, Камәр бер сүз әйтми көлемсерәп кенә киткән иде. Вафаның күңелендә нинди уй, ни төсле фикер булса да, ятимә кызның гыйффәтен югалтырга, гаризын сатырга, киләчәктәге рәхәтенең маясын, гомеренең башчысын, кадеренең сакчысын югалтып, яшьлегеннән файда итеп, үз рәхәтенә кызганыч Камәрнең киләчәктәге тормышын бозарга бер хәйлә, гакьлын алып аздырырга бер исәп кенә иде. Һәм Вафа теләгән нәрсәсенең булуына Камәрнең көлүләреннән, елмаюларыннан, күз карауларыннан аңлаганга, бөтенләй күңелен ышандырган иде. Вафа андый эштә тәҗрибәсез егет түгел иде. Күп кызларга бәла булган, күп хатыннарга җәфа булганга, төрле яктан алдарга өйрәнгән иде.

Вафаның исәбе бик коры, үзенчә бик тугры, корган хәйләләре, исәпләгән уйлары Камәрнең яшьлеген әрәм итеп, рәхәтен җую гына иде. Камәр кебек матур кызны, фәрештә төсле пакь гыйффәтле ятимә баланы, алдап-йолдап әрәм итеп ташларга теләү, Вафа төсле «абыз» исемен алган кешегә, динендә

ихласы бар, сүзендә [юк] булган егеткә, үзе өчен бер исемсезлек, Камәр ягыннан карасаң, бер газиз баланың бөтен рәхәтен югалту булганга, инсаниятсезлек булса да, Вафа: «Мин моңарча ничә кызны шулай иттердем, бер нәрсә дә булмады», — дип уйлый иде. Кызганыч, кызлар шул Вафаның аздыруы бәгъзесенә иреннән аерылырга, бәгъзесенә кызлыгында бала китереп бөтен дөнья алдында хур булырга; бәгъзесенә фәхешханә почмакларында изелеп, дөнья рәхәтен, кешелеген сатып тамак туйдырырга мохтаҗ булып, бөтен мөселманнар арасында кадерсез, гыйззәтсез булып, һәм дә дөнья, ахирәт рәхәтләрен җуюга сәбәп булуын белми иде. Һәм икенчеләренә мөселманлык дәфтәреннән имансызлыга, кешелек саныннан этлеккә чыгып, фахеш почмакларыннан җеназалары күтәрелү кебек бөтен галәме исламны рәнҗетә торган эшләргә башчы булуын да уйламый иде. Камәр кибеттән чыккач өенә кайта башлады.

Күңелендә бер хәсрәт, нәфесендә бер азгынлык сизүдә иде. Исәпләп, уйлап, Вафаның һәр сүзеннән бер төрле мәгънә чыгарып, Вафаның үзендә күңеле булырын белеп, хәтта Вафаның бәхәс сүзләреннән моны бик сөюен дә аңлаган кебек була иде. Кайткан вакытта Вафаның сөешү аңлата торган сүзләрен исәпләп, шатланып, эченнән көлә - көлә кайта иде. Ник сөенмәсен, ник шатланмасын?.. Үзен Вафа сөя, бәлки гашыйк булган. Адәм баласына сөелүдән кызык эш тагы ни бар!

Гомерендә укыган романнары «Җан Зөһрә» берлә «Бүз егет» кенә булганга, сөешүдә алдашуны уйламый, ялган мәхәббәтне белми дә иде. Шуның өчен үзенә гашыйк булган кешегә бу да гашыйк булырга тиеш дип белгәнгә, күңеленнән Вафага мәхәббәт баглаган иде. Белми иде ки, Вафаның гыйшкы бик очсыз, кемне күрсә — шуңар төшә, кемне ташлый — аннан бетә, «Егет күңеле җүләрдә, кызлар күңеле көләрдә» дигән сүзне дә ишеткәне юк иде. Алай булса да, Камәр моннан элек бер егет берлә дә йөрүне күңеленә дә керткәне юкка, Вафа берлә дуст булырга, Вафаны сөяргә күңеле күтәрелми, гакылы разый булмый иде. Камәрнең гакылында бер исәп, күңелендә бер уй булганга, йөрү илә йөрмәүдә аптырап калган иде. Төптәнрәк уйлап караса,

үзенә гашыйк булган кешене сөймәү шәфкатьсезлек дип белеп, аның хакы өчен генә булса да йөрергә тели иде. (Белмим, Вафа гашыйк микән?) Шул көенчә, Камәр Сәлимовлар кибетеннән икенче бер исәп алып кайтты.

Кәримә кызының кайтуына аш хәзерләгәнгә, алып кайткан нәрсәләрен урнаштырып, ашарга утырдылар. Камәрнең күңелендә һаман бер уй, ашаса-эчсә дә, уйнаса-көлсә дә Вафа күңеленнән чыкмый иде. Камәрнең бу уе кыла-нышларын да үзгәрткәнгә, Кәримәгә сиздермәслек булмаса да, Кәримәнең күңелендә икенче бер уй булганга, Камәрне җентеклән тикшереп торырга бушамый иде. Аның исәбендә Камәр уе да юк, җаучының китергән хәбәрләре иде. Кәримәне аласы кешедән тизрәк булуы теләнелгән иде. Урыны яхшы булганга, арага бер-бер кеше төшмәсен, шәйтан коткысы кермәсен дип, үзе дә тизрәк җайларга теләсә дә, икенче яктан, Камәрнең күңелен алырга теләве бу исәбенә бик тирес килә иде. Бер яктан, уйласаң, тиз кирәк, бер яктан исәпләсәң, сабыр кирәк! Кәримә ни эшләсен? Болай гына булмый, «Уйна да көл, исәплә дә бел» дип, эш җайларга бер гакыл уйлый иде. Кәримәне аласы кеше 40-45 яшьләрендә, хатыны үлгән ике балалы кеше булган шикелле, Камәр берлә икесен дә кабул итә иде. Балаларының зуррагы угыл, кечерәге кыз иде. Дәүләте бик зур булмаса да, җыйнак кына, сак кына, ашамы - эчеме яхшы гына тереклек итә торган кеше иде. Һәр яктан уйлаганда да Кәримәгә тиң булганга, Кәримә берлә җаучы арасында Камәр юкта вәгъдә дә булган иде. Бу көнне шулай уздырдылар. Иртәгесен Кәримәнең яшьтән бергә үскән, дустлык берлә вәгъдә куешкан, бер- берсенә «Дустым» дип сөйләшә торган Гайшә, Камәрне чакырып, шул тугрыдан сүз ачып ризаландырачак иде. Шуның өчен иртә торгач та дустым абыстай Гайшә Камәрне алып китте, Камәрнең төшләрендә күргән нәрсәләре Вафа гына булса да, көнендә икенче эш тә килеп чыкты, анасының бу исәбенә ничек разый булсын! Ләкин разый булмаенча ни эшләсен? Эш бу тугрыга йеткәч разый булмай ни кыла ала. Гайшә сөйләгәндә Камәрнең күзләреннән энҗе кебек яшь коела, төсе бер агара, бер күгәрә, авызыннан чыккан кайнар сулыш бөтен иренен көйдерә, күңелендәге хәсрәт бөтен тәнен кыздырып, шашу дәрәҗәсенә китерә иде.

Гайшәгә еглап кына җавап бирсә дә, эш бу теләгәнчә булмасын бик яхшы аңлаганга, күңелен ачар, хәсрәтен таратыр өчен башка уй төшерергә тырышса да, бу хәсрәт Камәрнең бөтен йөрәгенә ябышып, минут саен үсә генә бара иде. «Дустым» апаларына күңел ачарга барган Камәр күңеленә тау кадәр хәсрәтләр, бетмәс-төкәнмәс дәртләр алып кайтты. Кәримә кызының ни дәрәҗәдә көнче икәнен белгәнгә, никадәр хәсрәтләнәсен белсә дә, болай ук белдермәс дип уйлый иде, Камәр сабыр итә алмады, өйгә кергәндүк күзләре яшәрсә дә, өйгә кергәч кычкырып егларга башлады.

Кәримә: «Кызым; бәгърем, алай еглама!» — дисә дә, үзенең күзләреннән дә яшь акмакта иде. Камәрнең башын алдына алып туктатырга тырышса да, Камәрнең һәрбер хәсрәте яңадан ачылганга, атасы өчен, Габделәхәт өчен, анасы китүе өчен аерым-аерым еглый иде. Кәримә дә таш йөрәк түгел, ул да еглый! Мескинә бер кызның башына төшкән хәлләр!.. Боларның бу мәҗлесләрендәге хәсрәтле, кайгылы кыланышлар кемгә дә тәэсир кылырлык, кемне дә еглатырлык иде. Камәрнең авызыннан чыккан сүз «бәхетсез икәнмен!»гә башка булмаса да, бик күп мәгънә чыгарырлык сүз иде. Кызганыч кыз еглый-еглый йокыга китте. Кәримә Аллага шөкер кылып торуына башка сүз табар өчен самавыр хәзерләде. Кыз төшендә әллә ниләр берлә чуалып бетеп уянганда, йөрәге януыннан анасы берлә чәй эчсә дә, анасына сүз дәшәргә күңеле күтәрелми иде. Сөйли-сөйли Кәримә бераз җайлады, алай булса да Камәрдән көләч йөз, ачык чырай юк иде. Көн үтә бара, вакыт җитә бара, Кәримәләрнең туй көннәре дә җитте. Туй вакытында Камәр күзем күрмәсен дип «Дустым» абыстайларына киткән иде. Габделәхәт тә бу эшне белми түгел, белә иде. Ул да анасын көнли, атасын сагына иде, алай булса да, мәктәп тәрбиясе, әхлак файдасы хакында, Габделәхәт Камәр кебек кычкырып-бакырып егламаенча, үзен-үзе бастырып тора иде. Габделәхәт мәктәптә булганга үги атасы һәрвакыт күз алдында тормаячак иде. Шул сәбәптән Габделәхәт өчен бу көенечләр атасы искә төшкәндә генә икенче хәсрәт булачак иде. Кәримәнең яңы ире Камәр берлә икесен дә өенә алды. Камәргә үз фатирларыннан күчү, атасы хәзерләгән җиһазларны тарату, гүя атасының

исеме югалсын дигән кебек эшләү булганга, Камәр өчен бик авыр хәлләр, бик зур көенечләр иде. Габдерәшитнең фатирында әйберләр таралуы, хатынының иргә китүе, күз нуры газиз баласы Камәрнең еглавы, Габделәхәтнең моңлануы, берсе-берсе генә дә исән кешегә бөтен гомер буена истән китмәслек хәсрәтләр булганга, бу бәхетсезләрнең уйлары бик куркынычлы манзарәләр күрсәтүдә иде. Мескен Габдерәшит абзый исәнлек күзе берлә бу хәсрәтләрне күрсә, ни эшләр иде икән? Камәр атасының җеназасын күргәндә дөньяда моннан зур хәсрәт булмас дип белгән булса да, анасының туе анасына туй булса да, Камәр өчен атасының җеназасыннан да авыррак иде. Никадәр авыр булса да, Камәр анасы берлә бергә барачак иде. Чөнки анасыннан аерылу тагын өченче хәсрәт булмасын, Камәр зур булмаса да, мантыйк укыган шәкерт кадәре белә иде. Шулай итеп, Камәр анасы берлә китте. Камәргә әнисе берлә күчеп киткәч бик ямансу, күңелсез күренгәнгә, күп вакытта «Дустым» абыстайларына барып вакыт үткәрә иде. Адәм баласы ниләр күрми дә, ниләр генә уйламый!? Камәр дә әнисенең Мифтах абзый берлә торуына ияләшә башлады. Алай да күңелендә дошманлык, үч алу уе да корылган иде, Мифтах абзыйның Кәримәдә мәхәббәте юк түгел иде, Кәримәне бәлки элгәрге хатыныннан да [артыграк] сөя иде, ләкин Камәрне күргән саен Габдерәшитне искә төшереп көнли һәм Кәримәне дә Габдерәшиттән булган кызы янында булганга аны сагына дип белеп, күңеленнән бер кайгы, эч пошуы берлә изелә иде. Дөресте дә, Кәримә Габдерәшитне сагына иде. Ул иргә бару дигәч тә, барыбер Габдерәшит төсле булыр дип уйлаган иде. Ул алай булмый икән шул! Шуның өчен дә гакыллы карчыклар: «Ирем үлде, иргә бардым — имгәк алдым!» — дигәннәр. Кәримә кылган эшләренә үкенсә дә, артка кире кайтып булмый. Аерылып китәр иде, хатын башы берлә йорт-җирсез кая барсын да, ни эшләп торсын?.. Тагы, җитмәсә, Мифтахтан җөге дә бар иде. Һәр ягын исәпләп бетергәч, Кәримә ирекле-ирексез Мифтах берлә тормакчы, авыр булса да гомерен бергә үткәрмәкче булган иде. Мифтахның 13 -14 яшендәге кызы Васфибану Камәр өчен бик зур иптәш булган иде. Ләкин Камәрнең күңеленә башка уйлар, икенче исәпләр төшкәнгә, яшьлек фикерләре уянганга, башка

төрле иптәш кирәклегән сизә башлаган иде. Вафаның сурәте күңелендә бик береккәнгә, эзләгән иптәш күзләгәнгә бик тугры килә иде. Ләкин бик күп вакыт үткәнгә «Вафа онытмадымы икән?» — дип уйласа да, үзеннән-үзе үк: «Хәер, Вафа миңа гашыйк булсын да, мине онытсын! Ул ни дигән сүз!» — дип җавап бирә иде. Шул исәп берлә Камәр кәләпүш итәргә, дөрестен әйтсәк, Вафаны күрергә чыгарга хәзерләнде: күзен, башын карады, яхшы киемнәр киенде, эшләрен алып кибеткә китте. Шулсы бик гаҗәп ки, Кәримә кызының болай киенеп-ясанып, кыланып кибеткә китүеннән бернәрсә дә аңламады. Мескинә Камәрнең болай хәзерләнүләре һәммәсе үзен рәхәт галәменнән михнәт галәменә кертүгә бер сәбәп, үзене-үзе җафага салуга башчы гына иде. Ай, мескинәне тотып калучы булсачы, бу бәлаләрдән әллә котылыр иде. Бу уен бөтенләй үк яшерә түгел, дуст кызлары һәммәсе дә белсәләр дә, алар да тәҗрибәсез булганга, Камәрнең бу эштән күңелен биздерергә теләү түгел, бәлки дәртен генә арттыралар иде. Кайсы дустлары: «Мин хәрап булдым, исемем-чабым китте, миннән генә көлмәсеннәр әле, бу да шулай безнең төсле булсын!» — дип котырталар иде. Камәр, аларны дуст дип белеп, аларның сүзен тыңлый иде. Ник тыңламасын, алар моңарга зарарга сөйләмиләр,егет берлә йөрергә генә кушалар ич! Ул зарармыни?.. Шулай итеп, Камәр Сәлимовлар кибетенә юнәлде.

## III

Вафа никадәр заманнардан бирле Камәрне күрмәгәнгә Камәрдән уйлаган, исәпләгән өметләре бушка китте дип белгән иде. Шуның өчен Камәрнең кибеткә керүе берлә Вафа ни кыланырга белмәенчә елмаеп: «Сәламәт килдеңме?» — дип сүз башлады. Камәр дә бу юлы: «Әлхәмделиллаһ!» — дияргә оялмады. Вафа: «Эшләр чыгардыңызмыни? Бик сагындырдыңыз!» — дип сүзне озайтты. Камәр уйлый-уйлый үзен тилертеп, күңеленнән Вафаны гашыйк дип белгәнгә күрә: «Мин дә сагындым да,

вакытсыз булмый шул!» — җавабын да биргән иде. Вафа Камәрнең бу сүзләреннән эшнең җаен бөтенләй аңлады. Алай булса да сабырлык берлә эш кылырга кирәклеген белә иде. Шуның өчен акыртынлап алдамакчы булып, Камәрнең анасының китүен дә ишеткәнгә: «Сез анама киңәш итсәм харап булырмынмыни?» — дигән идеңез, әниеңез кияүгә дә киткән икән!» — диде.

Камәр, кызарып: Язмыш булгач, ни эшлисең!.

Вафа: Юк, әле мин синнән көләр өчен әйтмим, кешенең үзе кадәр анасы да файдасын күзәтә алмый дигән сүзем генә, шуның өчен һәр серләрне сөйли торган иптәш ясарга ирләр хатын алалар, кызлар кияүгә баралар.

Камәр: Бу әйберләрне хәйлә ясап сине күрер өчен генә чыктым.

Вафа: Мин дә кая күрергә белми, чыкса ярар иде дип тора идем.

Камәр: Чыктым инде, алай булса, миннән эш калмады.

Вафа: Миннән дә эш калмас, ләкин минем хәзер вакытым юк, кибеттән бушамыйм, сәгать алтыларда Державин бакчасында булырсызмы?

Камәр: Алай чыга алырмынмы икән соң?

Вафа: Кай вакыт дисеңез соң? Бер вакыт әйтеңез инде?

Камәр: Алай булса, сәгать алтыда булмаса да, йеделәрдә булырмын!

Вафа: Яхшы, вәгъдәңезне онытмаңыз!

Камәр: Мин онытмам, үзең саклан! Хуш булып торыңыз әле.

Вафа: Хуш, сәламәтлек берлә күрешергә насыйп булсын!

Шул сүзләр берлә Камәр кибеттән вәгъдә куешып чыккан иде. Өйгә кайткач та Камәр корган уен дөньяга чыгарыр өчен хәйләләр эзләргә башлады, әнисенә «Дустым» абыстайларга барам дип чыгасы да, кайтканда анда керер. Һәм Камәр әнисенә шулай дип чыгып китте. Кызганыч, кыз ни исәп берлә китте? Ни уй берлә йөри? Укучы бик яхшы белә ки, Камәрнең корган уйлары, эшләгән эшләре — һәммәсе үзен хәрап итәргә бер юл, киләчәктәге күрәчәкләренә бер башчы булып, Камәрне рәхәтеннән, сәгадәтеннән мәхрүм кылырга бер эш кенә иде. Шул исәп берлә Камәр Державин бакчасына барып та керде. Анда каранды, монда каранды, Вафа да килгән икән — очраштылар. Вафа Камәрне алып китте. Камәр берлә Вафаның ни сөйләгәннәрен, ни

эшләгәннәрен укучыларга калдырып, Кәримәләрнең өенә кайтыйк.

Кәриманең үги кызы Васфибану да 13-14 яшендә генә булганга, егетләр сөю дәрәҗәсенә йетмәсә дә, кыз булганга, Камәр берлә серләре килә иде. Камәр берлә дустлыклары бар һәм Камәр берлә «Сандугач» исеме берлә эндәшергә сүз куешканнар иде. Васфибану Камәрнең Вафа берлә араларында сүз йөргәнне белә иде, бу көнге эшләрен дә баштанаяк Камәрдән сөйләткән иде. Васфибану гакылсыз кыз түгел, егет берлә йөрүнең зарарлы икәнен дә белә һәм андый чабы киткән кызның кадере юклыгын да белә иде. Шуның өчен Сандугачына бераз үгет сөйләсә дә, Камәр үгет тыңлар дәрәҗәсеннән үткәнгә, һич файдасы булмаган иде. Васфибану, Камәрне кызганып, Вафа берлә йөрсә дә, үзен-үзе саклау бик кирәклеген сөйләгән иде. Камәр дә, сөйләгәндә аңласа да, Вафа янына чыккач аны да оныткан иде. Васфи, нәсихәтләренең файдасыз булуына, Камәр шулай бер белмәгән кеше берлә харап булуына разый булмаса да, Камәр күңеленнән разый һәм шулай булуны булдыклылык диеп белгәнгә, дуст-иш тугры килгәндә бер дә уйламаенча сөйли иде. Васфибануның «Бу ярамый!» диеп сөйләгән сүзләрен Камәр көнчелектән генә сөйли дип белгәнгә, күңеленнән аңарга да бераз дошманлык асрый иде. Гомер үтә бара, Вафа берлә Камәрдә артык яңы эш юк иде. Атнасына яки ун көнгә бер күрешеп торалар иде. Камәр үз исәбе берлә Вафаның җаучы кушып соратасын көтә иде. Вафа Камәрнең исемен онытыр дәрәҗәдә ташларга җай эзли иде. Камәр, Вафа өйләнмәгән, мине ала, дип уйлавы үзенчә тугры булса да, Вафаны мондый уйлаучы кызлар бер Камәр генә булмаганга, Вафа өчен бер дуэль булачак иде. Ләкин Вафа кайвакытта барасы җиргә бармый калып, кайвакытта башкача Камәрнең кәефен җибәрә иде. Вафаның мәкъсуды булганга Камәрне бөтенләй үк ташларга исәп иткән иде. Һәм Вафаның Камәргә икенчеләнүләре шул исәпнең бер ботагы иде. Камәр, Вафаның бу эшләреннән сабырсыз булса да, бара-тора аңлады, чөнки Вафа Камәргә аермачык ташлавын сөйләгән иде. Камәр Вафадан бу сүзне көтми, мондый өметләр уйламый иде. Аныңча, Вафа берлә рәхәтләнешеп бөтен гомерләрен бергә уздырачаклар иде. Һәм шулай уздырсалар, Камәр өчен яшьлеген әрәм итү дә зарарлы булмаячак иде. Ләкин

Вафаның күңелендә һичбер мондый уй булганы юк иде. Аның башта ук исәбе Камәрне алдап- йолдап, сәгадәтен бозып, яшьлегене дә әрәм итеп ташлау гына иде. Шуның өчен Вафа Камәрне икенче мәртәбә күрмәскә булып ташлаган иде. Камәргә бу хәбәрне ишетү бик җиңел булмады, бәлки бу хәбәрне ишеткәнче җаны чыкса иде, Камәр өчен җиңелрәк булыр иде, Камәр башыннан кичкән эшләрен берәм-берәм уйлап чыкты. Ни уйласа да, ни исәпләсә дә күргән эшләре һәммәсе үзенә кайгы, хәсрәт өчен генә булган шикелле, кылган эшләренең дә һәммәсе дә үз бәхетен үзе каплау, үз рәхәтен үзе жую гына икәнлеген аңлады. Ләкин хәзер аңлауда ни файда?!. Камәр Вафа берлә йөрмәгән булса, ичмасам, йөрсә дә үзен хәрап иттермәгән булса, бу кайгыларга, бу хәсрәтләргә төшмәячәк иде. Хәзер бер дә эшләмәс иде, бик аңлады да — эш үткән шул! Ай гакыл элгәрерәк булса да, Камәр болай булмаган булсачы!!. Инде ни эшләсен?!.

Камәр өчен Вафа берлә бергә торырга бер юл бар иде — ул да Вафа өстенә тел сөйләп, үзен хәрап итүен белдереп, хөкем берлә Вафага бару иде. Камәрнең алай итәсе килми иде. Чөнки алай иттереп көчләп барса да, рәхәт күрмәве билгеле иде. Шуның өчен бер сүз әйтмәенчә басып калмакчы булды һәм белдермәскә теләде. Дөресте генә, Вафаның ачуын китермәенчә, ялынып ипкә китермәкче иде. Шуның өчен Вафаның шәфкатен уяндырырга теләп, еглап-еглап Вафага хат язса да, каршы хәбәр килмәгәч, бөтенләй өметен өзгән иде. Камәр, шулай иттереп, үзен кешегә кыз иттереп белдереп торырга теләсә дә, боларның бу хәбәрләре шәһәр арасында җәелгәнгә, Камәргә бер йердән дә яучы килгәне юк иде. Камәр исәпләп-уйлап караса да, гаеп үзендә икәнен белгәч, йөрәге янып, эче пошып, үзен-үзе күрмәс дәрәҗәгә йетеп, әллә ниләр кылырга теләсә дә, Вафадан ни төрле җай берлә булса да үч алырга теләсә дә, эш нәтиҗәсез кала иде. Шуның өчен Камәр эченнән генә күбеп тора иде. Вафаның ташлавы Камәр өчен, бердән, сөйгәненнән аерылу, икенчедән, гомеренең сәрмаясын югалту булганга, Камәр бик зур бәлагә очраган, бик бөек каза күргән иде. Камәр шулай иттереп тол кыз булып гомерен үткәрә башлады. Васфибану кыз булып җитеп, җаучылар килә башлады. Һәм Васфибануны

кияүгә дә бирделәр. Васфибану кыз булса да, Камәр кебек егет сөймәгәнгә күрә, исеме-җәбе китмәгән иде. Шуның өчен, анасы булмаса да, бик чибәр төшләрдән җаучы килеп һәм бик яхшы йергә биргәннәр иде. Камәргә үзеннән өч-дүрт яшь кече сеңелесенең кияүгә китүе бик авыр тоелды. Моңарга ничек разый булсын! Ләкин разый булмый ни эшләсен?! Алла биргән казага адәм баласының чыдамый ни хәле бар?!. Камәр үзенең бу авыр хәлләрен ни эшләргә белми йөргәндә шәфкатьле Зөһрә абыстай күңелен алырга сәбәпче була иде. Зөһрә — асламчы карчык, хатыннар арасында әйбер сатып йөри иде. Һәм арлы-бирле кызлар арасында өшкереп-төкереп тә бераз кәсеп итә иде. Камәрләргә якын гына торганга, Камәр аларга барып, Зөһрә боларга килеп йөридер иде. Зөһрәнең башка кәсебе дә бар имеш! Гакылсызрак кызларны юлдан чыгарып, бераз акча да таба имеш, дип сөйләсәләр дә, Зөһрә абыстайның кулындагы тәсбихы, авызындагы өзелмәгән догасы, бетмәгән зикере, ул хәбәрләр дөрест түгелдер дип уйлата иде. Белмим, ни исәп беләдер, Зөһрә Камәрне үз янына ияләштергән иде?!.

Дөресте генә Зөһрә Камәрне сатып бераз акча алмакчы да, Камәрнең рәхәтен җуеп мескинә кызны тагы әллә нинди бәлаләр, хәсрәтләр чигәргә мәҗбүр кылачак иде. Һәм Зөһрә Камәрнең эшенең җайсызлыгыннан файдаланмакчы булып: «Фәлән кеше фәлән кадәре акча бирә, фәлән йергә генә барып килергә» дип әүвәл алдаса да, бара-тора Камәрне фахешханә почмакларында изелергә дә мәҗбүр иткән иде. Камәрнең анда-монда анасыннан рөхсәтсез чыгып йөрүе үги атасы Мифтах абзыйга бик авыр тоелган иде. Һәм Васфибануны да андый-мондый исемгә ияртмәсен дип курыкканга, беркөн [аны] чыгаруны файдага күрә иде. Мифтах абзый Камәрне ничек чыгарырга җаен тапкан вакытта, беркөнне Камәр бер сәгатьтә кайтасы кыз төнне һич кайтмый уздырды. Кәримә әүвәл дә «Дустым» абыстайлары Гайшәләрдәдер дип белсә дә, ахырыннан барып белешкәч, анда да булмады. Бу хәбәр Мифтах абзый өендә Кәримә абыстайның күңеленә яңы җәрәхәт ачкан иде. Мескинә хатын, кызының дуст-ишләреннән сорашты, белеште, ләкин һич хәбәр ала алмады. Шулай итеп, кичне бердәнбер кызыннан, сөекле

бәгырь йемешеннән, гомере буенча бер мәртәбә аерылмаган газиз баласыннан аерылып гомер үткәрергә тиеш булды. Кәримәгә бу төн бик озын, бу вакытлар бик авыр тоелды, хәтта Габдерәшит абзый үлгән көн, Габделәхәттән аерылган көн дә моңарга караганда җиңелрәк булган иде. Кәримә күзләре яшьле, күңелләре кайгылы көенчә бөтен кичне үткәрде. Гомерендә күргән рәхәтләрен, михнәтләрен уйлап карагач, күңелләре, гүя, бөтен дөньяның хәсрәтләренең, табигатьнең зәһәрләренең зәһәрләрен тәҗрибә кыла торган урыны кебек булган иде. Кәримә шул дәрәҗә хәсрәттә вакытында Камәр ниләр уйлый икән? Габделәхәт мәктәптә ни эшли икән? Анысын да белеп була. Камәрне Зөһрә абыстай, базарга гына чыгабыз, дип алып чыгып, вәгъдә куйган кешесенә тапшырган иде. Ул кеше дә, Камәр теләсә-теләмәсә дә ирексезләп исерткечләр эчереп исертеп, номерлардан бер номерга алып барып кунак иткән иде. Камәр иртәгесен айныса да, үзенең ничек булуын белеп, анасына бер сәгатькә генә дип чыгуын исенә төшереп, ни эшләргә дә белмәенчә катып калган иде. Инде анасына ни йөз берлә кайтып күренсен дә, анасына ни җавап бирсен?!. Камәр, шуларны исәпләп, һәммә кешегә болай булуы хәбәре чыга дип, бу яман аттан котылыр өчен бер хәйлә эзләсә дә, таба алмагач, бик кәефсезләнгән иде. Очраган кешесе моның бу кәефсезлеген сизеп, юатыр өчен анасы янына кайтмаенча гына, үзе генә дә тора алуын, хәтта бу егетнең кеше белми торган йердә генә фатир алып тотачагыны да сөйләп, Камәрнең кәефен китерергә тырышты. Камәр моны бөтенләй үк мәслихәт күрмәсә дә, шуңарга мәҗбүр булдым дип белеп, разый булган иде. Шулай итеп, ул көнне дә уздырдылар. Иртәгесен Бәдри егет Камәргә рус арасыннан бер фатир алып, фатирга куйган иде. Камәр әүвәлләре ул фатирда марҗалар берлә генә тора иде. Кич яисә көннең башка вакытларында Бәдри килеп хәлен белешеп, бер ике- өч сәгать утырып китә иде. Бара-тора Камәр янына икенче бер болгар кызы иптәш булып кергән иде. Бу кызның нинди кыз икәнлеген укучылар миннән дә бәлки артык белә торганнардыр? Нинди иде икән?.. Сатлык!.. Сатлык!.. Камәргә Бәдри ашавына-эчүенә, расхутына җитәрлек биреп торса да, кайсы көннәрне килми кала башлаган иде. Шул сәбәптән Камәр, очраса, Бәдригә башка егетләр

берлә дә аулакта гына утыргалый башлады. Иптәш кызына килгән дустишләре моны да бергә кунак итә башладылар. Бу хәзер Бәдригә бик авыр тоелды. Никадәр акчасын әрәм итеп Камәрдән болай мыскыллатасы килмәде һәм Камәргә, болай булса, бөтенләй акчасын, фатирын бирмәвен сөйләде. Камәр дә моннан соң сакланып кылмакчы булса да, беркөнне Бәдри Камәрнең башка кешеләр берлә утыруына тугры килеп, Камәргә моннан ары килмәячәген вә һич акча бирмәячәген сөйләп чыгып китте. Һәм Бәдри шул китү берлә Камәрнең икенче мәртәбә йөзен күрмәскә булып китте. Камәргә бу эш тагы бик җайсыз килде. Ни эшләргә дә хәле юк. Өенә кайтса да бөтен халык арасында хәбәре киткән!.. Ничек кеше күзенә бу йөз берлә күренсен!?. Өйгә кайтмаса, кая барсын!?. Ичмасам шул арада иптәше дә чыкты. Камәрнең фатирга акчасы, расхутка акчасы юк иде, һәммәсе кирәк! Фатирга акча сорыйлар! Кибеттә кенәгә тулган! Анда акча кирәк иде. Ни эшләсен?.. Кемгә киңәш итсен?.. Кемнән гакыл сорасын — һичкем юк. Ахырдан исәпли-уйлый торгач, Зөһрә абыстай исенә төште. Һәм шул кичне төнлә берлә генә Зөһрәләргә китте. Камәр Зөһрәләргә барганда атасының җеназасы чыккан йортка очраячак иде. Камәр шул йортта туган-үскән булганга, яшь вакытларын уйлаганда гел шул йорт искә төшкәнгә, бу йортны бик якын күрә иде. Һәм бу юлы да гүя әтисенең җеназасыны алып китүләре күз алдында торган кебек булганга, Камәрнең юлы яхшылыкта булмаса да, рәхәт кыз вакытларын искә төшереп сулыгып-сулыгып елаган иде. Исәпләгән вакытларында гүя әтисе сырхау имеш тә, Габделәхәт берлә Камәрне дә кулларыннан тотып: «Мине сез онытмаңыз, мин сезне онытмам!» — дип сөйли имеш. Камәр бу урында елап бөтен кичне үткәрер иде дә — мөмкин түгел! Мескен акрын гына елыйелый китте. Мифтах абзыйның өенә дә җитте. Камәргә бу өй икенче төрле нәрсәләр уйлата, күңелендә икенче фикерләр исәпләтә башлады. Нечкә пәрдә аркылы Мифтах абзыйның өй эчләре күренә иде. Өйләре матур иттереп зиннәтләнгән, түр башында Кәримә абыстай намаз укый иде. Васфибану киенгән-ясанган — киявен көтә иде. Камәр бу күренешкә каршы үзен бөтенләй онытып, эче пошып, бер көнләп, бер кызганып, бөтен матурлар галәмендә

аерым бер матур күзеннән энҗе төсле яшьләр түгеп, каралып торган күзенә кояш баеш манзарәләре бирүдә иде. Камәрнең дә айаганы анасы, көнләгәне Васфибану иде. Моның сеңелесе булса да, моннан ямьсезрәк булса да, ниндәй рәхәтлекләр күрә! Киявенең килүен нинди шатланып көтә иде! «Ай мин дә болай булган булсам!.. Болай булмас идем!..» диде. Һәм үзенең бөтен гомере буенча рәхәт күрүеннән өметен өзеп, еглай-еглай Зөһрәләргә киткән иде. Зөһрә Камәрнең күңелен алды, иртәгесен эшен җайламакчы булып калды. Бу көнгә кадәрге эше дә Зөһрә җайлавы берлә килгән иде ич!.. Алай иттереп, болай иттереп, Камәрне озатты. Һәм иртәгесен Зөһрә Камәр өчен фахешханәгә барып, үзенә алган никадәр акчага башка, Камәрне фатирдан, кибеттән йолып алырлык акча да алып, Камәрне дә алдап-йолдап фахешханәгә китереп кертте. Мескинә Камәр! Габдерәшит абзыйның сөйгән кызы! Фахешханә почмакларында изеләчәкмени? Нурлы аллы-кызыллы йөзләре, нечкә генә сызылган кашлары, озын-озын керфекләре, кара күзләре, зур кара сачләре, мөнтазам әгъзалары, фәрештә төсле йомшак күңелләре, дөньяның иң кабахәт йерләрендә, иң начар урынында, иң әшәке эшләр берлә бөтен гомере буенча харап булачак икәнмени?!

Моның өчен кем егламас? Адәм түгел, таш еглар!!! Бу эшләргә кем сәбәп булды? Ләгънәт аларга, ләгънәт!!! Камәр шулай итеп фахешханә сатлыкчысы да булды. Мескинәнең күңеле үзенең бу эшеннән һич разый түгел иде. Һәм шуның өчен, начарлыклардан ләззәт алмаенча, күп вакытта гомерен еглап үткәрә иде. Фахешханәнең тәрбиясе, бигрәк туктамаенча Камәрне исертеп тотулары Камәрнең холкына бик зур башкалык биргән иде. Элгәреге шәфкатьлелек урынына салмак вөҗдансызлык килеп, үзенең шул тормышын бөтенләй «ярый» дип белә башлаган иде.

Камәр Казанда шул эшендә ничә еллар гомерен харап итеп Оренбургка китте. Үз исәбе берлә, Оренбургка барып үзенең кем икәнен белгертмәенчә генә иргә барачак иде. Камәр бу уен бик яхшы аңлап уйлаган булса да, андагы бәгъзе гакылсызларның: «Иргә бару нигә кирәк әле? Яшь вакытыңда үз рәхәтеңне үзең сөрергә кирәк! Кияүгә картайгач та барырсың!» — сүзләре

берлә алданып, янәдән фахешханәгә кергән иде. Сатлыклык галәменнән, сәфаләт күзе берлә карасаң, Камәр Оренбургка килүеннән файда итте. Казанский Камәр дип Оренбургта исем тотты. Ни кадәр акчалар сарыф кылдылар, һичбер вакыт кунактан бушамады, алдыннан спирт вә исерткеч өзелмәде. Хәтта башка кызлар Камәр булырга бик кызыга да иделәр. Оренбургның бөтен шундый фахеш арасындагы кешеләрнең авызында Камәр иде. «Камәр ерга оста, Камәр куштан, Камәр матур» сүзләре берлә гел макталуда гына иде. Хәтта күп вакытларда фахешханәләрдә Камәр өчен низагъ да чыга иде. Ярамыймыни бер кәләпүшче кызына шул дәрәҗәләргә җиткәч!? Бу эшкә сәбәп булган Вафага рәхмәтләр укырлык бар!! Алай булса да, бу исемнән, бу макталудан Камәр ни файда итте?! Рәхәтләнеп ире берлә, бала-чагасы берлә гомер уздыра торган вакытын, бөтен гомерендә сачәк вакытын фахешханә почмакларында адәм балаларыннан һәр сыйныфның иң кабахәт кешеләренә юмаланып, куштанланып, бөтен җисмен, җанын, рәхәтен сарыф кылып тамагын туйдыра алды. Гыйффәтле хатыннарның күреп косасылары килә торган исерек, сасы, җайсыз кешеләр берлә изелеп, гомеренең иң кадерле сәгатьләрен, иң татлы минутларын, айнымаенча исереп хозур булып уздырды! Ярый әле хәзер Камәрнең матурлыгы да, куштанлыгы бар, шуның берлә тамагын туйдыра ала. Бара-тора, картая башласа, ни эшләр? Киләчәктәге сәгадәт сәрмаясен хәзер әрәм итте. Инде ни эшләр? Камәргә бу уй керә башлаган иде. Чөнки Оренбургка килүенә дә еллар үткәнгә, элгәреге кебек түгел, кадере беткән иде. Һәм һәрвакыт бизәнеп йөрүдән битләре җыерчыклана башлаганга, иргә бара алмаса, картлык гомерен ничек үткәрүләрен уйлап, үзен хәрап итүенә гаҗәпкә кала иде. Шуның өчен кай вакытларда иргә бармакчы да була иде. Ләкин моны кем алсын?!. Фахешханәдән кем хатын ала?!. Тагы, алса, ул кешедән ни рәхәт күрергә кирәк?! Камәр шул эшләрне уйлап хәсрәтләнә башлады. Дәрт бетерергә Камәрнең истигъмаль кыла торган исерткече булса да, ул да дәрт бетерү түгел иде, бәлки дәртле баштан гакылны гына китәрү иде, Камәрнең һәм фахешханә каршысында кадере киткәнгә, нинди булды, шул кеше берлә утырталар иде. Шуның берлә

Камәргә авыру эләкте. Фахешханәдән чыгардылар. Кая барсын?.. Үзе авыру, үзе акчасыз. Киемнәрен сатты. Ләкин ул нигә җитә? Бер яктан, авыруы көннән-көн арта бара, икенче яктан, акча бетте, һәм бөтен тәнен сырхау алды. Камәр ни эшләсен, кая барсын? Больниска барды. Ярый, кабул иттеләр.

## IV

Камәр больниска керүеннән бик шатланган иде. Анда ашарга-эчәргә һәммәсе хәзер иде. Ул гына бик зур эш түгел дә, Камәр кебек икенче көн ач йөргән кешегә бик кечкенә дә түгел иде. Икенче, сәламәтләнү ихтималы бар иде. Камәр больниста карала башлады. Ләкин һич файда итә алмый иде. Алай булса да, кешегә иярә торган чир булганга, бу көенчә чыгармыйлар иде. Бер ай уздырды. Камәрне никадәр йереннән газапладылар, бераз эшкә килә башлады. Алай да сәламәтләнеп бетәргә дүрт-биш ай кирәк иде. Камәр болай булуына да шөкерләр кылды. Сәламәтләнә башласа, ничек булса да бер сәламәтләнер. Гомер аңарга ул кадәр кадерле түгел! Тагы «больниста тормасам, рәхәт күрер идем», — дияргә хәле дә юк иде. Шулай итеп, больниста 6 ай гомерен уздырды! Авыруы бөтен тәненә җәелгән кебек, борынына да бер зур шеш ясаган иде. Камәрнең авыруыны бетерер өчен борыныннан шешне кисеп алдылар. Борыныннан шешне алганда азрак борын да киселгәнгә, уң яктан караганда Камәрнең битендә бернәрсә дә беленмәсә дә, сул ягыннан караганда гүзәл йөз өстендә ярты борын килешсезрәк күренә иде. Матурлыгы берлә бөтен Оренбургны алдаган кыз түгелме?!. Ни эшләде?!. Бусы бер кайгы иде, чыккач ни эшләр уе — икенче кайгы булды. Иске кәсебе дә ярамый. Болай булгач, иргә дә бара алмый. Ни эшләсен, бер-бер йердә асраулыкта, бер дә булмаса, йон юып-фәлән итеп тә тамак туйдырмакчы булган иде. Камәр кыш буен больниста үткәргән иде. Сәламәтләнеп килә башлаганда яз айлары кереп, көннәр матурланган иде. Сырхауларның сәламәтләнә торганнарын

больнис бакчаларына чыгарып та күңелләрен ачып йөртә башлаганнар иде. Камәр беркөнне бакчада утырганда фаэтон берлә ике мөселман хатыны больнис ишегенә туктадылар, һәм бакча аша больниска үтә башладылар. Камәр, боларны күргәч, шатланган кебек булды, ачуланган кебек булды, һәм көнләгән кебек булды. Ничек икәнен белмәсә дә, бу хатыннарның сәгадәтләренә кызыкканга, Камәр күзен алмаенча хатыннарга карап тора иде. Хатыннарның Камәргә әйләнеп караулары Камәрдә бөтенләй башка хис уяндырды. Камәр кызарды, йөзе бер каралды, бер агарды, бөтен тәнен эсселек алды, үзен-үзе атасы килде. Шул арада хатыннардан берсе, моңаеп кына Камәргә таба килеп, күзләрен яшәртеп: «Камәр апа, сәламәтме?» — сүзен сөйләде. Камәр аны танымаска теләгән булса да, исеме берлә әйткәч, база алмады, сул йөзен яшеребрәк кенә: «Аллага шөкер, үзең сәламәтме?» — дип, болар арасында сүз башланды. Бу хатын Камәрнең үги сеңелесе, Сандугачы Васфибану иде. Васфибануның угылы Рәшит Оренбургта мәктәптә укый иде. Мәктәптә сырхауланып мәктәп больнисыннан алынып гомуми хастаханәгә бирелгән иде. Һәм атасына-анасына мәктәп тарафыннан телег- рамм берлә хәбәр йебәрелгән иде. Телеграмм барганда Васфибануның ире Сәлим Москвада булганга, Васфибану, телеграмм берлә хәбәр алышып, Оренбургка угылын күрергә, сәламәтләнсә, алып кайтырга, сәламәтләнмәсә, җыймакчы булып килгән иде. Янындагы хатын Оренбургның Мортаза бай хатыны иде. Ул Васфибануның ире Сәлим байның ширкәт берлә сату итә торган кешесе иде. Шул сәбәптән Васфи аларга кунак булган һәм больниска угылын күрер өчен дә икәү килгәннәр иде. Васфибану Камәрне күргәч угылын бөтенләй онытты. Камәрнең башыннан үткән хәлләрне берәм-берәм уеннан кичерде. Никадәр сөйләшеп, бервакытны атына килеп күрәсен вәгъдә кылып, Васфи апасыннан аерылды. Васфибануның очравы, аның хәленең рәхәтлеге, тормышының сәгадәтлелеге Камәргә икенче уй уйлаткан иде. Һәм үзенең сәфаләт галәмендә бөтен гомерен әрәм итүен, гафилсызлык берлә үз рәхәтен югалтып нинди эшләргә мөбтәля булуын исәпләп, күрдеге мәшәкатьләр вә сырхауларны исенә төшереп, киләчәктәге авырлыкларын да күңелдән

кичерткән иде. Белмәенчә, яшьлек берлә кылган начарлыклары өчен үзен-үзе шелтәләп, кылган гөнаһларын уйлап, Камәр күзләреннән яшьләр агызырга башлады. Васфибануның шул дәрәҗә рәхәтләнеп торып та, никадәр вакытлардан бирле күрмәгән үги сеңелесенең шулкадәр йомшаклык, шәфкать берлә сөйләве моңарга бик гаҗәп тоелды. Зира Камәр сәфаләт галәмендә йөреп, әшәке кешеләр арасында торып, холык- табигысе дә бозылган иде. Бөтен дөньяда шундый дөрест уйлы, яхшы күңелле кешеләр барлыгын уйламаган чакта, моның хәлен айап кызганып еглавы, Камәргә яшь вакытларын исенә төшерүенә, ата-анасының, Габделәхәтнең хәлләрен уйлавына сәбәп булды, бакчага утырып, башын тотып, үзенең урамда кечкенә вакытында уйнаган иптәш кызларын, әтисенең һәркөнне базардан кайтуын көтеп торган вакытларын, аның кулыннан әйберләрен Габделәхәт берлә сөенә-сөенә алуларын, кич берлә әнисенең кәсепләрне сорашып, әтисенең бәгъзе көнне «яхшы булды!», бәгъзе көнне «чак!» дигән сүзләрен уйлап, еглый иде. Һәм Габделәхәтнең, иркәләнеп, бер әтисенең итәгенә, бер әнисенең итәгенә ятуларын исенә төшереп, үзенең шул вакытларда аталы-аналы матур бер кыз икәнлегене төшенеп, хәзерге үзенең кайда икәнлегене, ничек килдегене, нәрсәләр сәбәп булдыгыны, үзенең кем икәнлегене вә киләчәктә кем булачаклыгыны төшенеп, атасының: «Шәкерткә бирермен, остазбикә булырсың!» — дигән сүзләрен уйлап, һәм шул эшкә, шундый дәрәҗәгә ярарлык була торып та, үзенең начарлыклары берлә хәзер «фахишә!!» исеме берлә яд кылынуына көеп, уйлап, бу эшләргә күңеле разый булмаенча эченнән көеп еглап утыра иде. Атасының үлүләрен, Вафа берлә сөешә башлауларын, Габделәхәтнең мәктәпкә китеп туганыннан аерылуларын, иске фатирындин, туган йортларын таратып, үги атасының өенә күчүләрен, Вафа берлә сөешүенә рәхәтләнеп йөрүләрен, Вафадан харап иттерүләрен, Вафаның ташлауларын, сөйгән Вафасыннан аерылуларын, тол көенчә кыз дип торуларын, бу олуг булса да, исеме-җабы киткәнгә күрә Васфибануның кияүгә китүләрен, үзенең Бәдри берлә дустлыкларын, Зөһрә абыстайның иткән эшләрен, Казанда, Оренбургта фахешханәләрдә торуларын, сырхауларын, фәкыйрь булып ач

булуларын, больниска керүләрен, үзе берлә бергә торган сеңелесенең бала-чага анасы булып рәхәтләнеп гомер сөрүләрен, үзенең больнистан чыкканнан соң ашарына-эчәренә таба алмаячагын уйлап, кыскасы гына, башыннан кичкән нәрсәләрне һәммәсен хәтереннән кичереп, «уф!!» дип сулап сулыгып-сулыгып егларга башлаган иде. Камәр, никадәр егласа да файда итә алмасын белсә дә, үзен-үзе тыя алмаенча еглауда иде. Ничә сәгатьләр еглап, аш вакыты йеткәч ашарга керсә дә, Камәргә аш булмавы Камәрнең сәламәтләнеп чыгар көне йеткәнне белгерткән кеби, Камәрнең ач-ялангач, мохтаҗ йөрергә вакыты җитүне дә белгертү димәк иде. Камәргә әйберләрен биреп, үзенең иске киемнәрен киертеп, больнистан чыгарылды. Камәр үзенең сәламәтләнүенә шатланачак урында, киресенчә, кайгыруда иде. Чөнки Камәр гомеренең рәхәт уздыра торган вакытын этлектә уздырганга, үзенең сәрмаяи мәгыйшәтен җуйганга, бөтен кеше әйтергә чирканырлык «сатлык кыз» исемен күтәргәнгә, дөньядан рәхәт күрүеннән өмет итәргә һич җай табалмый иде. Шулай итеп, Камәр больнистан аерылды. Ләкин ничек тамак туйдырсын? Кайда торсын? Ни берлә дөньясын кичерсен? Бу сөальләргә җавап бирү бик авыр иде. Төрлечә уйлап караса да, җай таба алмады, үзең туйдырырга да аш рәтли алмады. Ни эшләсен соң, элгәрерәк данлыклы вакытларында дүрт-биш кеше кунак итәргә чакырып йөргән бакчада бүген ач утырып торырга рөхсәт булса да разый иде. Һәм дә кереп утыргач, куып чыгармауларыннан утыру мөмкин икәнлекне белде. Алай булса да узган-барган һәммәсе моңарга күз очлары берлә карап, Камәрнең юк кәефен дә бозарга сәбәп булалар иде. Кичкә кадәр шул бакчада уздырды. Кунарга кая барсын? Уйлый торгач, фәкыйрьханәгә бару исенә төште. Һәм дә акрын гына, бер аяк адымын бер тамчы күз яше берлә санап, бәхетсез Камәр анда таба китте. Мең бәла берлә элгәреге вакытларында күргән саен җирәнә торган, сасып беткән карт марҗалар берлә кунарга керә алды, ләкин карынының ачлыгы Камәргә йокы бирмәүдән башка, шул начар халыкларның исләрен искәтеп тә яткыра иде. Бу көн шулай бик мәшәкатьле көенчә үтеп, бу көннән дә котылды. Ләкин һаман ач!! Кичкә кадәр һичнәрсә таба алмады. Садака сорарга базмый, хезмәт итәргә урын табалмый иде. Кичкә

таба йон юа торган йергә барырга исенә төште. Ләкин ничек барсын?!. Ике тәүлек була, ашаганы юк!.. Бармаса, ачка үлә! Ни эшләсен? Әкертен генә Урал (Җаек) суы буена китте. Бик акыртын гына барып белеште. «Иртәгә эш булса булыр!» сүзен ишеткәч сөенүе Вафаның: «Сине сөям!» — дигән сүзен ишетүдән ким булмады. Кичне шунда урман арасында үткәрде. Иртәгесен эшкә тотынырга, ничек булса да җалынып, бер абыстайдан берәр кисәк икмәк алып ашады, аның берлә дә карыны тукланмаса да, кич тую дәрте берлә эшкә башлаган иде. Бу көнне шулай акыртын гына уздырып эшләгән акчасын алды. Бу акчаны ничә айлардан бирле күргәне юкка һәм файдалана алмаганга гаҗәпкә калып карап тора иде. Акчасына азык алып ашады. Бөтенләй үк хәл керерлек булмаса да, әүвәлге көннән яхшырак булган иде. Бу кичне дә урманда балаганда кунды.

## V

Йон юучылар арасында берсе Камәр булган шикелле, башкалары да кайсы Камәрдән дә күп дөнья күргән, кайсы Камәр булырга йөри торганнар иде. Һәммәсе дә «урман — өем, урыс ирем» дип, урман эчендә теләсә кем берлә кич үткәрәләр иде. Камәрдә ул көнне тамак туйдыру кайгысы гына булса да, бара-тора икенче дәртләр дә төште. Әүвәл бер егет берлә генә маташа башласа да, ахырдан кем очрады, шуның берлә китте. Җәй буе Урал буенда эт туе кебек халык арасында Камәр дә гомерен үткәрде. Кем очрады, шуның берлә йөрүеннән корсаклы булып, янә бер авыру эләкте. Һәм бик каты авырый башлады. Шулай итеп, корсаклы көенчә хастаханәгә керде. Камәрнең бу сырхавы элгәреге сырхавына башка булмаса да, монысыннан терелүен уйларлык түгел иде. Чөнки Камәр караган саен артка китә бара иде. Бара-тора Камәрнең баласы туар вакыт йетте. Үзе авыру булганга баласын китерә алмады, ничә көннәр мәшәкатьләнеп ятса да, бабкалар сүзенә караганда, баланы

ярмаенча китерә ала алмавы беленеп, Камәрнең эче ярылып, баласы алынса да, бала үле күрелде. Һәм Камәр дә җан бирде. Камәрне больнистан алып күмделәр.

## Хатимә

Камәрнең дөньяга килгәненнән бирле үткән вакыйгаларын уйлап карау, эшләгән эшләренең сәбәбен тикшерү, чиккән михнәтләрене искә төшерү, яхшы диянәтле фамилиядән булдыгы хәлдә, фахешханә почмакларында, урман араларында, адәм балаларына иң бәднам бирә торган бер эшне кәсеп иттереп торып вә шул кабахәтлектән хасил булган баланы табарга авырып вафат булуы, бөтен инсаннарның күңелләрен чиркандыра торган, үзен кыяматкә кадәр шул начар исем берлә яд кылырга сәбәп була торган хәлләрдәндер.

Камәрнең бу дәрәҗәдә бөтен галәме инсаниаттә мәнфур улып, мөселманлыкка һич ярамаган хәлләрдә булуы өчен һәр мөселман еглап кына калмаенча, шул начарлыктан милләтемезнең башка кызларыны сакла- мак өчен һәркем кулыннан килгән куәтне сарыф кылмак тиеш, бәлки лаземдер. Камәр вакыйгасында күрелдеке шикелле кызларымызның сәфаләт галәменә керүләренә сәбәп булучылар Вафа илә Зөһрә кеби ике төрле кешеләрдер. Бунлар, бердән, мәгъсумә бер яшь баланың бөтен гомерен харап итдекләре кеби, милләте исламиямезгә бик зур кимчелекләр китерә торган «сатлык» галәменең ачылуына да сәбәп улмакталардыр ки, бусы илә бөтен исламиюн тарафыннан ләгънәтләр илә зикер ителмәктәләрдер. Шундый вакыйгаларның күплеге сәбәбеннәндер ки, бөтен дөнья мөселманнары арасында сатлык кызлар тәрбия кылу безнең Казан халкында гына чыкмыштыр, вә бу вакытка кадәр дә шул халыкта гынадыр. Бу вакыйга кеби гаҗәп гыйбрәтле вакыйга бер генә улмаенча, шул галәмдә йөргән кызларымыз, ирләремезнең һәммәсендә дә мөхәррирләр язып бетерә алмаслык эшләр булмактадыр ки, «Раббем

һәммәмезне сакласын» сүзеннән башка бер эш эшли алмыймыз.

*Мөхәммәдгаяз.*

Мөхәммәдгаяз әфәнде!

«Кәләпүшче кыз»ны укыдым. Аны баскан өчен сезгә ни әйтергә дә белмим. Бу китап миңа шулкадәр тәэсир кылды — һич әйтеп бетерә алмыйм. Бәлки һәммә укыган хатын-кызга шулай була торгандыр, мин анысын белмим. Мин үз тугрымда гына сөйләмәкче булам. Ни өчен миңа ул кадәр тәэсир кылды диярсезме? Ник кылмасын? Минем үземнең бердәнбер кызым «Кәләпүшче кыз»дагы Камәр кебек булган иде. Шуның өчен китабыңызның бер юлын укыган саен бер сыгым күз яше берлән үземнең кызымның хәлләрен уйладым. Ул Камәрнең әүвәлге мәхәббәтләре минем күңелемә шулкадәр ут якты — һич әйтә алмыйм.

Чөнки алар минем сөекле кызым Маһиҗиһанның миңа еглый-еглый Таһирны сөюен сөйләгәннәрен исемә төшерде. Күз алдыма кара сачләре тузган, күзләре яшәргән, йөзенә үлек төсе кергән көенчә: «Әни, әйтмә! Ул да мине сөя, мин дә аны сөям!» — дигән сүзләре, тавышлары берлән колагыма хәзер дә ишетелгән кебек тоела. Ай кызым, ай бәгърем! Синең сөюләрең никадәр чын күңелдән булса, Таһирныкы да шулкадәр «дөрест» икән!!

Минем кызым Маһиҗиһан Камәр төсле булмады. Аның сөйгәне никах берлән алды. Шундыйн соңмы? Шундыйн соң. Менә кара инде, хәзер дә күземә яшь тулды, ни әйтергә дә таба алмыйм. Шуннан соң минем кызымның сөйгән Таһиры кызымның еглауларына, җалынуларына ка- рамаенча аермасынмы?! Менә мәхәббәт нинди була икән ул!! Мин ни эшләргә дә белмәдем. Кызыма караган саен еглыйсым килә иде. Аның берлән сөйләшергә сүз таба алмый идек. Ул шулкадәр бәхетсез иде — аны нинди эш, нинди сүз белән дә юатыр хәл юк иде. Ул үзе дә минем берлән сөйләргә сүз тапмый иде. Кайвакытта: «Әни!» дип дәшә иде дә, күзләреннән яшь мөлдерәргә тотына иде дә, тагы сөйли алмый идек. Кызым шулай итеп өч-дүрт атна торды. Бара-тора

акрын гына сөйләшә башлады! Ләкин шулкадәр зәһәрләнде, һич кеше аның берлән сөйли алмый башлады. Элгәре гомерендә бер мәртәбә каршы дәшмәгән кыз мине тотып талый башлады. Үзе еглый, үзе тирги иде. Мин йөрәгенә чыдый алмыйча кыйлана дип сабыр итеп тора идем. Бара-тора һичбер кешенең сүзенә ышанмый башлады. Аныңча һәммә кеше алдакчы иде. Мин бер-бер зур кешенең сүзен әйтсәм: «Ул да алдый, син дә алдыйсың!» дип кул гына селти иде. Мин: «Бу эш яхшы түгел, бу — фәлән», — дисәм, «Дөньяда андый эш юк, эшли алсаң, һәммәсен эшлә!» — дия башлады. Мин моңардин саташмасын дип бик курка башладым. Менә бервакыт киенде дә, миндин сорамый-нитми чыкты да китте. Минем эчем пошып калса да, бераз башым тынып торсын әле дип артындин чыкмадым. Бер ике-өч сәгатьтин соң кызым кайтты. Белмим шатланганга, белмим башка нәрсәгә, кергәч тә кычкырып-кычкырып көләргә тотынды. Мин никадәр сорасам да, җавап бирмәде. Шуннан соң кичкә таба кызым тагы егларга тотынды. Мин ни эшләргә белми аптырадым да калдым. Тагы бер сүз сөйләми башлады. Кайвакытта гармунда уйный иде. Гармуны шулкадәр менә моң була иде, аның уйнаганы исемә төшсә, хәзер дә күзләремдин яшьләрем ихтыярсыз агарга тотына. Никадәр вакытлар үткәннән соң кызым әллә нишләп авырый башлады. Бераз саташып әллә ниләр сөйләп ятты да терелде. Ләкин бөтенләй башка кеше булып терелде. Бик уйлап, көйләп йөрүчән булды. Бик юк нәрсәдин тавыш чыгаручан булды. Беркөнне өйлә намазы укырга тотынган идем, менә кызым егларга тотынды. Элгәре акрын-акрын гына башласа да, бара-тора үксеп-үксеп егларга тотынды. Мин намазымны ашыга-ашыга укысам да, бетерә алмадым, актык сөннәтемне укыганда кызым: «Әни!» дип алдыма килеп егылды да, тагы сулыгып-сулыгып егларга тотынды. Мин дә чыдый алмадым. Намазым бозылды. Бер-беремезгә карашып, бер сүз дә сөйләмәенчә бик озак еглаштык. Кызым миңа шулкадәр кызганыч күренде, шулкадәр, ул көнге кадәр аяныч булганын һич белмим! Төсләре саргайган, йөзенә әллә нинди, карасаң еглыйсыны китерә торган төс чыккан иде. Күзләре һаман миңа карап әллә нәрсә әйтергә теләгән кебек күренә иде. Бераздан соң кинәттән: «Әни, минем корсагым бар!» диде дә,

битен каплап тагы егларга тотынды. Мин ничек бастырырга белмәдем. Ул көнне кызым миңа һәрвакыт йөзен күрсәтергә оялган кебек күренә иде. Һичбер вакыт минем йөземә башын күтәреп карамады. Кич булгач та тиз генә ятты. Иртәгесен карасам, кызым юк! Кая?.. Ник китте? Һич белмәдем. Көн буе көттем — кайтмады, сораштым — табылмады. Кая китте кызым?!. Ничә көннән соң, шунда бер Алланың ләгънәте суккан йер бар бит, «җиңгәчи»ме диләр, шунда барып кергән дип ишеттем. Ай Раббем, ни көннәр күрәсем бар икән! дип, кызымны алырга киттем. Сораштыра башладым, һич әйтмиләр, кызымны качырганнар. Әллә нинди исерек хатыннар үземне сүгә башладылар. Мин егларга тотындым. «Минем кызым ич ул, миңа күрергә дә ярамыймыни?» — дип талашырга тотындым. Бер өмет тә калмагач, үзем чакырып караем әле дип: «Маһиҗиһан! Балам, чык! Чык, балам, бер күреп кенә китим!» — дип әйткәч, әллә кайдан кызым атылып килеп чыкты да миңа карап: «Ник монда килдең? Монда син килә торган йермени?» — дип кычкырды да, тагы үксеп-үксеп егларга тотынды. Озак үтмәде, аны бер хатын әллә нинди әшәке сүзләр әйтеп алып кереп китте. Минем дә шулай өметем киселеп кайтып киттем. Шуннан, билгеле, баласы булды. Ләкин гомерсез туган икән, өч атналык булгач та үлде. Минем кызым шул рәвешчә сатлык кыз булып тора башлады. Ул эшкә хәзер дүрт ел булды инде. Кызым миңа һәрвакыт килеп- китеп йөри иде. Беркөнне иртә берлән чәй эчмәенчә үк бераз эшләремне карап тора идем, менә кызым кулына виноградлар, алмалар күтәреп килеп керде. Мин бик шатландым. Чәй эчәргә тотындык. Кызым чәй янында бик моң иттереп гармун уйнады да: «Китәргә вакыт, әнкәй, Уфага китәм, берәр айдан кайтырмын», — дип, минем берлән еглап-еглап, муеныма асылынып күрешеп, күзләреннән яшь агыза-агыза бер алдына, бер артына карап китте. Мин шулай калдым. Уфадан бер хат алдым, сәламәт дип язган. Менә әле өченче көн алган хатымда иптәш кызы сөяркә итеп тота торган еврее көнләп буып үтерде дип хат язган. Кичә полиция дә килеп шулай үлгәнен белгертте. Минем хәсрәтемнең нинди авыр икәнлеген бәлки сез аңларсыз дип, бу хатны яздым, гаеп итмә, чибәр егет. Менә хәзер үзең уйлап кара инде, минем кызым Маһиҗиһан кызганычмы?

Әллә «Кәләпүшче кыз»дагы «Камәр» кызганычмы?

*Маһиҗиһан анасы Гафифә.*

Бу хатның маэлен бер дә бозмаенча, гыйбарәсен бераз төзәттем. Чөнки үзе язган көенчә гыйбарә кылсам, бик күп кешегә аңларга авыр булыр иде.

*Мөхәммәдгаяз.*

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Димагымның тәфкираты* — миемдә (башымда) туган фикерләр.

*Заигъ* — әрәм, файдасыз.

*Айау* — кызгану.

*Мәсләк* — караш.

*Зира* — чөнки.

*Мотлак* — һичшиксез.

*Лязем* — тиеш.

*Сүи зан* — яман фикер.

*Тарыз* — рәвеш, ысул.

*Бәян* — сөйләү, аңлату.

*Хөсусән* — бигрәк тә.

*Гаҗәба* — кереш сүз, «кызык» мәгънәсендә.

*Кәррә* — тапкыр.

*Тәнбиһ* — кисәтү.

*Маэл* — эчтәлек.

*Кариэ* — укучы.

*Мөтәшәккир* — рәхмәтле.

*Шифаһи* — телдән.

*Тәхрирән* — язма.

*Тәкъризат* — уңай бәя.

*Дәрҗ* — теркәү.

*Гыйлавә* — кушымта.

*Һаман* — бу вакытта.

*Нан* — ипи.

*Һәйәте җәдидә* — яңалык күренеше.

*Фасикъ* — бозык.

*Абыз* — укымышлы кыз.

*Гариз* — бу урында: яманат.

*Тирес* — кире.

*Дәртләр* — бу урында: борчылулар.

*Итү* — илтү.

*Сәрмая* — кыйммәт.

*Зикер* — бу урында: «Алла» исемен кабатлау.

*Мөнтазам* — матур, төзек.

*Сәфаләт* — түбәнлек.

*Сәгадәт* — бәхет.

*Истигъмаль* — файдалану.

*Атына* — атап.

*Мөбтәля* — дучар.

*Зира* — чөнки.

*Сәрмаяи мәгыйшәт* — тормыш кыйммәте.

*Искәтү* — иснәтү.

*Хатимә* — ахыр, эпилог.

*Диянәтле* — дин тотучы.

*Бәднам* — яман ат.

*Мәнфур* — җирәнгеч.

*Мәгъсумә* — гөнаһсыз.

*Исламиюн* — мөселманнар.

**Кәләпүшче кыз.** — Хикәяне басарга рөхсәт С.Петербургта 1900 елның 20 мартында бирелә. Хикәя авторның укучыга мөрәҗәгать итеп язылган кереш һәм йомгаклау сүзләре белән Казанда Мөхәммәтҗан Кәримов вө бирадәрләре матбагасында 1900 елда басылып чыга. 30 бит. Имза: Мөхөммәлгаяз. Әсәр Казанда 1898 елда язылган. Хикәянең икенче басмасына рөхсәт С.-Петербургта 1902 елның 6 мартында бирелә. Әсәр беренче һәм икенче басмалары турында авторның укучыга ике мөрәҗәгате, йомгаклау сүзе яки «Хатимә"се, хикәянең беренче басмасын укыган бер хатынның хаты белән Казанда 1902 елда Б. Л. Домбровский типографиясендә басылып чыга. 42 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый.

Әсәргә беренче «рецензия" не цензор Смирнов яза: «Один богатый татарин, кичившийся своим мнимым благочестием и верностью старине и который враждебно относится к таким новшествам среди молодых татар, как чтение газеты и иллюстрированных книг,.. сам развратил и довел до окончательной погибели одн бедную татарку, жившую дотоле честным трудовым эаработком.» *(С.-Петербургтагы Үзәк дәүләт тарих архивы, 777 ф., 4 тасв,, 8 эш,10 к.)*

Матбугатта Г. Исхакый беренче тапкыр «Кәләпүшче кыз» әсәре басылып чыгу уңае белән телгә алына. *(«Тәрҗеман» гәзитәсе, 1900, 22 июль, 26 нчы сан; 19 сентябрь, 34 иче сан).*

Повестьны укып чykканнан соң Йосыф Акчура болай дип та: «Гаяз илә иң әүвәл Парижда таныштым: мәктәп аркадашы Садрыйда (С. Максудида) аның портреты һәм «Кәләпүшче кыз»ы бар иде. Татар әдәбиятыннан иң күп тәэсир белән укыган китабым «Кәләпүшче кыз» булды. Мәмләкәттән ерак идем. Ул заман зиһенемне Казанның карлы, тавышсыз, җансыз көннәре, кыска буйлы татарларның йомшак киез итекләре илә Пләтән урамында сак кына йөрүләре, мәчет манараларыннан бер да еракларга сузыла алмаенча эре-эре яуган кар кисәкләре арасында югалган азан тавышлары, хөласан, татарлар Казанны тутыра иде. «Кәләпүшче кыз»ны укыр көн шул Казанда гомер иттем һәм милләтемә чыккан иң тәһликәле, иң агулы бер чуанның сызлавын үз рухымда хис кыларак гомер иттем. Хикәянең икенче басылуында гыйлавә

ителгән хатны укыганда чыдый алмадым, «Корнея Латән» мөсафирханәләреннән беренең хөҗрә — караңгы, фәкыйрь бер бүлмәсендә япа-ялгыз, мескен татар кызының сөкүте, фәлякәте, атасының тәэсири шәфкате өчен озын-озын егладым.

Ул заманнан игътибарән фикеремдә тәмамән урнашкан иде: милләттәшләрем арасында ике чын әдип җитешә, берсе — хәссас, атәшле милләтпәрвәр, идеалист вә романтик Гаяз, икенчесе — гасаби, тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих (Ф. Кәрими)».

*(Й. Акчура угылы. Гаяз әфәнде, - Казам мөхбире. 1906, 5 ноябрь, 179 сан.)*

Г. Исхакыйның 1907 елда дөнья күргән «Зиндан» повестена Сәгыйть Рәмиев белән Габдрахман Хөсәенов язган кереш мәкаләдә: «Кәләпүшче кыз» китап базарында бик зур роль уйнап, мөхәррире Гаяз әфәндегә «тагар әдибе» исемен алып бирә һәм «мөхәррир» таҗыны кигезә,» — диелә.

Текст әсәрнең икенче басмасыннан алынды.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 50-78.
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова